ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 542 от « 12» 05 2017 г.

Мамадыш районы урта гомуми
белем бирү оешмаларының 10 сыйныф
укучылары белән хәрби хезмәткә
әзерләү җыеннары үткәрү турында

Россия Федерациясе гражданнарына хәрби хезмәт нигезләре буенча беренчел белем бирү инструкциясенә таянып, гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүне камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы 10 класс укучылары өчен 2017 нче елның 17 нче майдан алып 19 нчы май аралыгында МББУ "Олыяз Лицее" базасында 3 көнлек хәрби хезмәткә әзерлек җыеннары уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Хәрби коммиссариатының Мамадыш муниципаль районы буенча бүлеге башлыгы А.В. Синкевичка һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты МКУ "Мәгариф бүлеге" башлыгы И.Н. Габдрахмановка 2017 елның 5 маенда гомуми белем бирү оешмаларының хәрби хезмәт нигезләре укытучылары һәм хәрби җыенның җитәкчеләре белән хәрби хезмәткә әзерләү буенча методик өйрәтү дәресләре уздырырга тәкъдим итәргә.

3. Җыеннар үткәрү чорында 1 нче кушымта нигезендә уку җыеннары җитәкчеләре исемлеген төзергә.

4. Татарстан Республикасы хәрби комиссариатының Мамадыш районы (муниципаль) буенча бүлек башлыгы подполковник А.В. Синкевичка ОБЖ укытучыларын теоретик яктан әзерләүне оештыруда һәм укыту атуларын уздыруда ярдәм күрсәтү буенча тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасына (Сергеев А.М.) хәрби җыеннарны үткәрү өчен каралган акчаларның, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының МКУ "Мәгариф бүлегенең" нормативлар билгеләнгән сметасына нигезләнеп, үз вакытында күчүен тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты МКУ "Мәгариф бүлеге" башлыгы И.Н Габдрахмановка:

- Хәрби җыенда катаншучы яшүсмерләрнең исмелеген , профилактик медицина тикшерүләре нәтиҗәләрен исәпкә алып (Мамадыш районы үзәк больницасы белән берлектә) төзергә, укучыларны хәрби җыен үткәрү урынына алып килүне, җыенда катнашучыларны сыйфатлы тукландыруны оештырырга;
- уку-укыту процессын, хәрби- патриотик тәрбия бирүне уку-укыту тематик планына туры китереп оештырырга;

7. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Дәүләт автоном сәламәтлек оешмасы “Мамадыш раоны үзәк шифаханәсе” баш табибы Д.Ф.Хазиевка лагерь территориясендә медпункт эшен оештырырга, медперсонал, кирәкле медикаментлар һәм эвакуация чаралары белән тәэмин итәргә;
- Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Мамадыш районы буенча бүлегенә җыен үткәрү урынында тәүлек буе кизү торуны оештырырга;
- район мәдәният бүлеге мөдире С.П.Спиридоновка укучыларның буш вакытларында мәдәни- массакүләм чаралар программасын оештырырга.

8. Укучыларның тормыш куркынычсызлыгы өчен җаваплылыкны хәрби хезмәткә өйрәтү җыенының җитәкчесе С.С. Михайловка һәм хәрби хезмәт нигезләре укытучыларына йөкләргә.

9 . Әлеге карарны интернет мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

10. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче И.Э.Фәттахов

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы
Башкарма комитетының
12.05 2017 ел, № 542
Карарына кушымта

УКУ ҖЫЕННАРЫ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ ИСЕМЛЕГЕ

1. Җыеннар җитәкчесе- С.С.Михайлов, ОБЖ буенча оештыручы-укытучыларның район методик берләшмәсе җитәкчесе, Красногорка урта мәктәбенең ОБЖ укытучы-оештыручысы;
2. Җыеннар җитәкчесенең уку-укыту эшләре буенча урынбасары - Донсков О.А., Мамадыш шәһәренең 1 нче санлы урта мәктәбенең ОБЖ укытучы-оештыручысы;
3. Җыеннар җитәкчесенең тәрбия эшләре буенча урынбасары – Шәрифуллин А.М., Түбән Яке урта мәктәбенең ОБЖ укытучы-оештыручысы;
4. Җыеннар җитәкчесенең спорт эшләре буенча урынбасары– Хәбибуллина Р.Н., физкультура укытучыларының район методик берләшмәсе җитәкчесе, Олыяз лицее физкультура укытучысы;
5. Җыеннар Коменданты – Гибадуллин И.Т., Олыяз урта мәктәбенең ОБЖ укытучы-оештыручысы;